БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» 11 2024 ел № 267

**Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алына торган күчемсез мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда, алар арендага ала торган муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 175 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 8 апрелендәге «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 174 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алына торган күчемсез мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда, алар арендага ала торган муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2021 елның 12 августындагы «Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алына торган күчемсез мөлкәтне милеккә сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда, алар арендага ала торган күчемсез мөлкәтне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 251 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов